Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге
Сосновый бор поселогында
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«25» ноябрь, 2025 ел № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы «Кнәз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге Советының 2019 елның 05 декабрендәге 12/4 номерлы карары нигезендә Сосновый Бор поселогы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2026 елда яшәү урыны буенча Кнәз авыл җирлеге Сосновый Бор поселогы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм **I, II** төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ("Сосновый Бор бистәсендә бистә эчендәге асфальт һәм вак таш белән эшләнгән юлларны ремонтлау һәм реконструкцияләү);

- урамнарны яктырту җайланмасы (Сосновый Бор торак пунктында яктырткычлар сатып алу, урам яктырткычларын монтажлау һәм урнаштыру);

- проектлаштыру, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын төзү һәм ремонтлау (Сосновый Бор бистәсендәге сuүткәргечне ремонтлау);

-янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (проектны эшләү һәм массакүләм ял итү урыннарын төзекләндерү, махсус аренда.техника, яшелләндерү).

2. РФ Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын Князево авыл җирлеге территориясендә теркәлгән взнослардан азат итәргә.

3.Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге Сосновый Бор поселогы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге Сосновый Бор поселогы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Кнәз авыл җирлеге башлыгы И.М.Вилданов